СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ХАЛЫК ГАЗЕТАСЫ
НАРОДНАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА

Газета 1931 елның 1 июленнән бирле чыга | №126 (7455) | 22 октябрь, 1992 ел. ПӘНҖЕШӘМБЕ | Бәясе 4 тиен.

**ДУСЛЫК**

## Хөрмәтле укучылар!

**Кабат исегезгә төшерәбез: «Дуслык», «Дружба», «Туслах» район газетасына язылу дәвам итә. Газетага үзвакытында язылып калырга киңәш итәбез. Аның еллык бәясе 78 сум.**

◆ *Бер колхоз хәбәрләре*

## Кышлатуга хәзерлек

«Таң» колхозында терлекләрне кышлату чорында уңышка ирешеп эшләү өчен мөмкинлекләр тудырылган. Маллар җәйләүдә чакта терлекчелек биналары әйбәтләп ремонтланды һәм агартылды, абзарлардагы тирес чистарту транспортерлары, автоэчергечләр—һәммәсе төзәтелде.

Сыерның сөте —телендә, ди халык. Хуҗалыкта җәмәгать маллары өчен пыклы азык базасы булдырылды, сусыл һәм тупас азыклар запасы ел буенча җитәрлек тупланды. Агымдагы елның 9 аенда терлекчеләр планнарын уңышлы тәмамладылар. Иң әйбәт нәтиҗәгә Кәшифә Шәкүрова иреште. Ул үзе караган сыерлардан дәүләткә 660 центнер сөт тапшырды. Һәр сыердан бу күрсәткеч 3007 килограмм тәшкил итте һәм ул колхоз буенча беренчелекне яулады. Халидә Галимова, Нажия Билданова, Минзада Гәрәева да сынатмадылар, бу чорда алар 520—600 центнер сөт җитештерделәр.

x x x

Мөгезле эре терлек симертүчеләр арасында бозаулар караучы Рәфика Зиятдинова алда бара. Ул 32 центнер үсеш алып, 9 айда һәр баш малның тәүлеклек артымын 630 граммнан киметмәде.

Разил Шәрәпов белән Зәйтүнә Мөхәммәдиева да начар эшләмәделәр, һәр башның тәүлеклек артымын 600 граммнан киметмәделәр. Алар тырышлыклары, уңганлыклары белән коллективның хөрмәтен яуладылар. Контроль үлчәүләр гомумән үсеш алуның былтырдан артык булачагына өметләндерә.

**З. ШАҺИЕВА.**



Минсабир Хәбибулла улы Миннеголов бригадасы скважиналарга капиталь һәм җир асты ремонты цехында һәрвакыт алдынгылар рәтендә. Бригадир бердәм һәм тырыш коллектив туплауга иреште. Әсфат Мөхетдин улы Газизов—шул бригаданың бер члены. Коллективның хезмәт уңышларына аның да лаеклы өлеше керә, билгеле.

РӘСЕМДӘ: «Норлатнефть» НГДУсы эшчесе Ә. М. Газизов вахтада.

Н. Квашнина фотосы.

## Кара. Чагыштыр. Нәтиҗә ясa

**Район хуҗалыкларында ит җитештерүнең торышы.**

Беренче багана—хуҗалыклар исемнәре, икенче—1992 елның 9 аенда мөгезле эре терлекләрдән, өченче—дуңгызлардан алынган тәүлеклек үсеш (граммнарда).

| | | |
|---|---|---|
| Синдряков исем. | 710 | 378 |
| Ульянов исем. | 548 | 196 |
| «Правда» | 541 | 210 |
| «Восход» | 584 | 265 |
| Мичурин исем. | 539 | 214 |
| «Россия» | 553 | 263 |
| Хафизов исем. | 579 | 317 |
| «Путь к коммунизму» | 489 | 49 |
| Муса Җәлил исем. | 407 | 244 |
| «Родина» | 577 | 280 |
| «Игенче» | 523 | — |
| «Большевик» | 592 | 272 |
| «Заветы Ильича» | 463 | 344 |
| «Знамя Октября» | 563 | 189 |
| «Алга» | 339 | 210 |
| «Комбайн» | 401 | 218 |
| XXI партсъезд исем. | 551 | 264 |
| «Татарстан» | 485 | 246 |
| «40 лет Победы» | 529 | 293 |
| «Чишмә» | 525 | 221 |
| «Таң» | 600 | — |
| «Москва» | 755 | 248 |
| «Үрнәк» | 532 | — |
| «Лесная поляна» | 568 | — |
| «Кондырча» | 476 | — |
| Кузнецов исем. | 460 | — |
| «Заря» | 583 | — |
| «Чирмешән» | 488 | — |
| «Ленинский путь» | 590 | — |
| «Беренче май» | 638 | 350 |
| «Яшь көч» | 646 | 420 |
| «Төрнәс» совхозы | 422 | 230 |
| «Мамык» совхозы | 434 | 225 |
| «Рассвет» совхозы | 550 | 350 |
| «Сөлчә» совхозы | 416 | 210 |
| Хуҗалыкара берләшмә | 615 | — |
| «Дуслык» | 554 | — |
| Район буенча | 536 | 316 |

## Тырыш хезмәтчәннәр

«Яшь көч» колхозы терлекчеләре быелның 9 аен әйбәт кенә күрсәткечләр белән тәгәлләделәр. Хуҗалык савучылары арасында 1 урынны Шәрифулла Хәмидуллин белән Минсара Вәлиева алдылар. Бу чорда алар үзләре карамагындагы һәр сыердан 2470 килограмм сөт саудылар. Бу исә узган елның шушы чоры белән чагыштырганда 336 килограммга артык. Ә колхоз буенча бу күрсәткеч һәр сыердан 2430 килограмм тәшкил итә һәм ул узган ел белән чагыштырганда 234 килограммга артык. Шунысы куанычлы да, дәүләткә алар тапшырган сөт бары 1 нче сорт белән генә кабул ителә. Алар шулай еллык планнарны арттырып үтәү өчен җиң сызганып эшлиләр.

**Л. БОЙКОВА.**

## Тормыш-көнкүреш фонды

Түбән Кама шәһәр һәм район хакимияте башлыгы каршында тормыш-көнкүреш фонды быел май аенда гына оештырылган иде. Бүгенге көндә аның исәбенә төрле предприятие-оешмалардан 3 миллион 200 мең сум акча керде, шуның бер миллионын «Нефтехим» җитештерү берләшмәсе бирде. Колхозлар, совхозлар да үз взносларын керттеләр. Җыелган сумманың 30 проценты мохтаҗларның тормыш-көнкүрешен яхшыртуга, калган өлеше социаль һәм мәдәният-көнкүреш тармакларын үстерүгә тотылачак.

## Ишеттегезме әле...

Үзбәк фининспекторлары ел башыннан бирле налоглардан яшерелгән миллиардтан артык сумманы ачыклаганнар. Болар арасында 8 миллион сумнан артык налог түләмәгән «Нур Әнвәр Банк» коммерция банкы рекордчы булып тора. Моның өчен аны властьлар лицензиядән мәхрүм иткән. Әмма банкирлар борын салындырмый, «8 миллионга без теләсә нинди лицензия сатып ала алабыз»,—ди алар.

x x x

Тибет тауларының әллә кайдагы ерак бер авылы Донджида яшәүчеләр арасында соңгы 50 ел эчендә бер үлүче дә булмаган. Шушы көннәрдә генә анда яшәүче берәүнең 242 яше тулган, татып 188 кешенең яше 130дан артып киткән. Донджи авылының бар кешесе дә бик яшь кыяфәтле, чирчинкегә зарлапучы юк. Алар экологик яктан бик чиста табигатьтә, аның белән килешеп яшиләр, нигездә фасоль, дөге һәм балык белән тукланалар.

x x x

Ташкент шәһәрендә этәч сугыштыру буенча рәсми булмаган чемпионат ачылды. Җиңүчегә куелган сумма—500 дән 5000гә кадәр. Уңышлы үткәрелгән сугышлардан этәчләр чынлап торып «алтынга» әйләнә, бер сезонда хуҗаларга алардан 100 меңгә кадәр табыш керергә мөмкин. Шуңа күрә дә этәч сугышларын бик афишаламыйча гына һәрдән читтәрәк үткәрәләр.

x x x

Пенза шәһәренең администрациясе дачаларны угрылардан саклау максатында 20 кешедән торган махсус взвод булдыру өчен акча бүлеп бирде.

Беренче көннән үк милиционерлар, бакчалар талауга көйләнгән, яхшы оештырылган махсус җинаять төркемнәре һәм аерым кешеләр бар, дигән нәтиҗәгә килгәннәр. Шушы көннәрдә генә, мәсәлән, Удмуртиядән килеп, 100 дача басарга өлгергән адәмне тотканнар. Ни өчен бу төр җинаять белән шөгыльләнүе турында сорагач, бакча юлбасары: «Бакчачыларны күралмыйм!» дип җавап биргән.

x x x

Биробиджан янындагы уртак урыс-кытай «Интерагро» предприятиесе үзенең кырларыннан иң якынча хисаплаулар буенча гына да быел 400 центнер яшелчә һәм карбыз җыеп алырга тиеш булган. Әмма хуҗалар «урак өсте»н башларга җыенып яткан арада, җирле басып алучылар уртак предприятиене төп башына утыртып куя: кырларда бер генә карбыз да, яшелчә дә калмый. Кытай ягы предприятиене торгызуда ярдәм итәргә җыенмый.

## Җылы атмосферада

«КОМБАЙН» КОЛХОЗЫ. Гадәт буенча урып-җыю тәмамлангач уракта катнашучы төп көч—механизаторлар, комбайнчылар, шоферлар, ындыр табагы эшчеләре өчен оештырыла торган бәйрәм быел 18 октябрьдә үтте. Хуҗалыкның быел чынлап торып бәйрәм итәрлек сәбәпләре бар. 2015 гектарда бөртекле культуралар, 180 гектарда чөгендер уңышын үзвакытында җыеп алып, дәүләткә ашлык һәм татлы тамыр тапшыру планын арттырып үтәде ул.

Бәйрәмдә шулар турында сүз алып барылды, алдынгыларның исемнәре телгә алынды. Ә алар биредә аз түгел. Комбайнчылар арасында ашлык суктыруда 1 урынга чыккан Марс Әхмәтов та, игеннәрне теземнәргә салуда районда иң алдынгы саналган Илгиз Шәйдуллин белән өченче лидер, тәҗрибәле комбайнчы Ясәви Әхмәдиев та, башкалар да—һәммәсе уракта тир түгеп, йокыларын онытып хезмәт куйдылар. Алар суктырган ашлыкны ындыр табагына, элеваторга ташучылар Маннур Сәйфетдинов, Равил Сәмәрханов, Дамир Фәтхетдинов, ындыр табагында ашлык күчерүчеләр Нәкыйп Мәхмүтов, Гали Нәбиуллин, Фәнис Фәсахов, чөгендер комбайнында эшләүчеләр Әүхәт Галимов, Тәлгать Мәсгутов турында да бик күп җылы сүзләр әйтергә мөмкин булыр иде.

Шулай колхоз игенчеләре җылы аралашу, үзләренә тиран хөрмәт атмосферасында бәйрәм иттеләр.

**Р. ГЫЙМРАНОВ,**
колхозның баш агрономы.

*Синең кешеләрең, авыл!*

# Эшләп тапкан бәхет кадерле

АЛАРНЫ бер карауга тиз генә танырмын да димә. Гадәттә эш киеменнән, тиргә-тузанга баткан килеш күрергә гадәтләнгән игенчеләр бүген кияү егетләре кебек ыспайлар, йөзләрендә елмаю балкый.

—Исәннәрмесез! Бәйрәм белән сезне!

—Исәнмесез, менә чакыргач, кунакка килдек әле.

Район культура йортының фойесы аралашу, күрешү, очрашу шатлыгыннан ничектер яктырып, җылынып киткән сыман. Гомер бакый иген иккән механизаторлар, шоферлар төркем эченнән чордашларын, дусларын эзлиләр, ирләрчә тыйнак шатлык белән бер-беренең җилкәләренә кагылып алалар.

Аларның күбесе безгә дә таныш. Әнә «Алга» колхозыннан комбайнчы Рәшит ага Галиуллин белән мин уракның беренче атналарында басуда очрашкан идем. Ул чакта игеннәрне теземнәргә салуда иң әйбәт күрсәткеч аңарда иде. Комбайнчы шул темпны урак ахырына кадәр саклый алган. Бүген ул тулы хокук белән күкрәген киереп бәйрәм итә ала: ЖРБ-4,2 белән игеннәрне теземнәргә салуда иң күп мәйдан район буенча да аңарда исәпләнә: 517 гектар. Исең китсен: карап торырга салмак кына хәрәкәтле, акрын кешегә охшаган механизаторга шундый җитезлек каян килгән диген син?

«Комбайн» колхозының өлкән механизаторы Ясәви ага Әхмәдиевны да хәтерлим. Иске генә комбайн белән басуда солыны теземнәргә салганда очрашкан идек. Төпле акыллы, сөйләшергә бик ипле бу агай үзе дә инде олы, комбайны да иске, яшьләр белән ярышырга авыррактыр аңа, дип уйлаган идем. Бәхеткә, ялгышканмын. Ясәви аганың да исеме җиңүчеләр рәтендә: ЖВН-6 белән игеннәрне теземнәргә салуда ул район буенча өченче урынга чыкты.

Чү, янәшәдәге бу ике өлкән агай да таныш түгелме соң?

—Шулай, Совков Иван мин, дөрес,—ди агайларның чаярагы.—Ә бу дустым Онгин Алексей Кузьмич, комбайнчы.

Әлбәттә, алар! Һәр иксен эш вакытында да, намуслы хезмәтләре өчен ничә тапкыр газета битләрендә дә күрдек бит инде. Хәер, башкача мөмкин дә түгел. Һәр икесе 30 елдан артык «Правда» колхозында эшлиләр, исемнәре алдынгылыктан төшкәне юк.

—Быел без Кузьмич белән бик әйбәт эшләдек. Аның бункерыннан иң беренче бушатылган уҗым бодаен мин кабул иткән идем, иң соңгысы —карабодай олавын да ындыр табагына мин озаттым,—ди Иван Миронович урак хәлләрен искә төшереп. Шулай, бик тату, көйле эшләделәр алар уракта. Әнә Алексей Кузьмич СК-5 белән дә бункерыннан 7 мең центнерга якын ашлык бушатты. Комбайнына икенче сезон гына әле, сәгать кебек келдерәп эшли. Әй яшьрәк чагы булсамы—һич икеләнмичә «Дон»га алыныр иде. Хәзер дә буш вакыты чыккан саен Петр Михайлович Семеновның куәтле машинасын балалар кебек сокланып карый, таныша, тел шартлата. Менә, уйлап таптылар бит җайлы техника, рәхмәт төшкерләре. Теземнәрне су кебек эчә. Үзе дә аңарда эшли алган булыр иде яшьрәк чагында, хәзер дә әнә иң кыен участокларны аңа тортү ягын карыйлар бит. Кайда куш теземнәр, кайда юл кырые—өлкән комбайнчы түзми, шунда юнәлә.

Агайлар быелгы урактан канәгатьләр. Хуҗалыктагы комбайнчылар Семенов, Александр Макаров һәм аның ярдәмчесе Николай Григорьев, ашлыкны теземнәргә салучы Валерий Аввакумов һәм башкалар турында да сокланып, яратып сөйлиләр.

—Коля Григорьевны әйтүем. Шулкадәр күңелен биреп эшли, әле укучы гына бит. Менә кемнәргә ышаныч багларга була иртәгесе көн өчен,—ди Алексей Кузьмич комбайнчы ярдәмчесен кат-кат телгә алып. Әйе, иртәгәге кәнгә ышанычлы алмаш булуы өлкәннәр өчен зур шатлык. Димәк, иген үсәчәк, димәк, икмәк булачак.

«40 лет Победы» колхозыннан Таһир Хәлимов белән Рифкать ага Сафиуллиннарның хезмәт дуслыгы күпләр сокланырлык. Комбайнчы Таһир белән шофер Рифкать ничәмә-ничә еллар уракта бергә эшлиләр инде.

—Ике «Нива» туздырдык, инде 3 нче ел «ДОН»да бергә эшлибез,—ди Таһир. Быел ул куәтле комбайн белән 10662 центнер ашлык суктырды, бу—колхозда икенче күрсәткеч. Ә Сафиуллин биш минутка да тоткарламыйча ашлыкны ташып торды. Инде менә бәйрәмдә дә алар янәшә, алар бергә.

Бәйрәм тантанычылары җыела торалар. Алар—кунаклар да, хуҗалар да бүген.

«Мамык» совхозыннан шоферлар Анатолий Гаврилов, Василий Захаров та, «Россия»дән ике Владимир—Михеев һәм Мандрейкин да, «Дуслык»тан Вәгыйзь Җиржизов һәм башкалар да—һәммәсе горурлар да, бәхетлеләр дә бүген. Намуслы хезмәт аша килгәнгәдер, аерата тансык, кадерле бәхет ул алар өчен.

С. ХӘЙРУЛЛИНА.

# Хокукларны белеп

*Актуаль интервью*

**Соңгы елларда экономик кризис тудырган бер күренеш —эшсезлек безнең тормышыбызда да очрый башлады. Ул проблема бездә ни дәрәҗәдә кискен тора һәм аның киләчәктә нинди юнәлеш алуы ихтимал—бүгенге сөйләшүебез шул хакта,** Әңгәмәдәшебез — эш һәм хезмәт белән тәэмин итү бюросы мөдире Р.А. Әхмәтсәгыйрова.

—Роза Абдулловна, бүгенге көндә безнең районда эшсезлек күренеше ничегрәк тора?

—Беләсезме, безнең районда аны чагыштырмача кискен проблема димәс идем мин. Ел башыннан безнең бюрода 39 эшсез кеше исәптә тора иде, аның 38се эшсезлек буенча пособие алып торды. 16сы ел дәвамында эшкә урнаштырылды. Хәзер, 1 октябрьгә алар 6га гына калды, аларның 3се минималь хезмәт хакы күләмендә пособие алып торалар.

—Бездә эш урыны кыскартылу яки башка сәбәптән эшсез калган гражданнар еш кына үз хокукларын белмичә югалып калалар.

—Әйе, андый хәл белән без еш очрашабыз, шуңа кыскача гына аның тәртибен аңлатуны кирәк дип саныйбыз. Иң элек, теге яки бу сәбәптән эштән кыскартылган кешеләргә алар эшләгән предприятие, оешма ике ай дәвамында хезмәт хакы түләргә тиешлеген онытмагыз. Әгәр ул эштән азат ителеп 10 көн эчендә безнең бюрога теркәлсә һәм без аны эш белән тәэмин итә алмасак, безнең белешмә нигезендә 3 нче айны аңа оешма түләргә тиеш. Инде шуннан соң да эш таба алмасак, без аңа беренче көннән үк эшсез дигән статус бирәбез. Бу очракта бер шарт бар: әлеге статусны алу өчен кеше кимендә 6 ай алдан Татарстан Республикасында даими яшәүче итеп теркәлгән булырга тиеш. Шуннан соң инде бездә исәптә торган кешеләрнең бурычларын да әйтеп үтик: ул айга 2 тапкыр безгә килеп регистрация үтәргә тиеш, бу таләп үтәлмәгәндә, без закон нигезендә пособие түләүне туктатабыз. Әгәр таләпләр үтәлә икән, без 12 ай буе пособие түлибез, аның соңында да ярдәм итә алмасак, материаль ярдәм күрсәтергә хокукыбыз бар. Тагы бер нәрсә бар: әгәр бездә эшсез дип теркәлгән гражданкага 53 яшь тула икән, без аны 2 ел алдан —53 яшеннән пенсиягә чыгару турында район социаль тәэминат бүлегенә мөрәҗәгать итә алабыз. Агымдагы елда 2 хатын-кыз шулай пенсиягә озатылды инде, октябрь аенда тагын шундый 1 гариза уңай хәл ителергә тора. Хатын-кызлар колагына: әгәр оешма-предприятие 2 яшь баласы булган хатын-кызны эштән азат итә икән, 3 ай үтеп тә эш табылмаса, республика **Министрлар** кабинеты карары буенча, безнең белешмә нигезендә оешма аңа 6 айга чаклы уртача **хезмәт хакын түләргә тиеш.**

—Роза Абдулловна, укучыда сез ел дәвамында шул берничә кешегә хезмәт күрсәтү белән генә шөгыльләнәсез икән, дигән ялгыш фикер тумагае...

—Юк-юк, зинһар алай уйлый күрмәсеннәр. Моннан тыш безгә гомумән эш эзләүчеләр дә еш мөрәҗәгать итәләр. Бездә ел башында 152 шундый категория кеше теркәлгән иде, хәзер 25әү исәптә торалар. Алар белән дә без эшлибез. Шуның өстенә хезмәткә кагылышлы сораулар белән гражданнарга бушлай консультация дә бирәбез. Быел, мәсәлән, безгә шулай 190 кеше килде, һәрберсенә махсус карточка ачылды. Моннан тыш, хәзер яңа категория—качаклар бар бит әле, алар белән дә без эшлибез. Хәер, бусы —аерым сөйләшү. Аннан —бюроның төп бурычы эшсезләр белән генә эшләү түгел, ә эшсезлекне булдырмау, аны алдан кисәтү бит, шуны да онытмагыз.

—Бусына бәлки үзегез иркенләбрәк тукталырсыз...

—Бездә һәр елны Октябрь районында яшәүчеләрне эш белән тәэмин итү программасы эшләнә, ул администрация башлыгы тарафыннан раслана. Биредә без үзебездә булган мәгълүматлардан чыгып, алдагы елда ихтимал эшсезләр санына прогноз бирәбез. Бездә булган мәгълүматлар нәрсәдән гыйбарәт? Алары иң элек оешма-предприятиеләрдән штат кыскартылу ихтималы турында мәгълүматлар. Гомумән, «Закон о занятости» буенча эш тәкъдим итүчеләр безгә һәрчак буш эш урыннары, эш шартлары, түләүле җәмәгать эшләре турында мәгълүматлар бирергә тиешләр.

—Роза Абдулловна, ә шулай да бездә эшләп эшсез калу куркынычы янаган оешма-предприятиеләр бармы? Бу ни белән бәйле?

—Беләсезме, бәхеткә каршы юк. НГДУ, НУРБ, геофизика кебек зур-зур оешмаларда да андый кыенлыкны бик уйлап җиңә киләләр: үзләрендә өстәмә цехлар, ярдәмче хуҗалыклар, кече предприятиеләр ачалар, ничек тә кешеләрне авыр хәлдә калдырмаска тырышалар. Ә безгә мөрәҗәгать итүчеләрнең күбесе—сәүдә, көнкүреш хезмәте өлкәсеннән, аларның барысы да диярлек иң аз якланган катлам—хатын-кызлар булуы безне борчый, әлбәттә.

Аерым профессия кешеләренең үз белгечлекләре буенча эшкә урнаша алмаулары исә үзебездән дә тора. Әйтик, соңгы вакытта 99 нчы СПТУда бухгалтерлар курсы ачылу белән бу һөнәр ияләре бик күбәеп китте, соңгы 2 елда тәрбиячеләр белән дә шундый ук хәл. Инде ярдәмгә мохтаҗлар өчен координатларыбыз: без район администрациясе бинасында беренче катта утырабыз, телефоныбыз—2—14—67.



Тыныч, сабыр табигатьле Вахит ага Кәрим улы Әхмәтов турында сүз чыкса: «Алтын куллы механизатор ул безнең»,—диләр колхоз җитәкчеләре. Ул гомере буена колхозда механизатор булып эшли, мастер-көйләүче хезмәтен дә алып бара. Хәзер терлекчелектә МТЗ-80 тракторы белән малларга азык ташый, кышын савучыларны фермага эшкә йөртә. Вахит ага һичкайчан эштән баш тартмый.

Рәсемдә: «Чишмә» колхозы тракторчысы Вахит Әхмәтов эш вакытында.

## *Үзгәрешләр кертелә*

Соңгы вакытта икмәккә бәяләр үсү сәбәпле икмәк заводы продукциясен сатып алу сизелерлек кыскарды. Завод коллективы бу хәлдән чыгу өчен үтемлерәк продукция җитештерү мөмкинлекләрен барлый. Шундый эзләнү—үзгәреш нәтиҗәсе булып, 14 октябрьдә кибет киштәләренә беренче тапкыр яңа төр продукция —200 граммлы сайка һәм югары сортлы оннан пешерелгән 300 граммлы «Ситная» булкасы чыгарылды.

Авырлыгы зур булмаган бу булка әйберләре сатып алучылар күңеленә хуш килер дип уйлыйбыз. 15 нче октябрьдә кибетләргә тагы бер яңа төр икмәк—720 граммлы Дарницкий ипие чыгарыла башлады.

Завод коллективы бу юнәлештә башка мөмкинлекләрне каравын да дәвам итә.

Р. АНАНЬЕВА.

